**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«23» 11 2021 ел Яр Чаллы № 4227

Боерган авыл жирлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча документларны эшли башлау турында

Боерган авыл жирлеге Башкарма комитетының гаризасын карап, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32, 33 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Боерган авыл жирлеге Советының 2014 елның 6 августындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча документларны эшли башларга.
2. Проектлаштыруны территориаль планлаштыру документлары нигезендә техник регламентлар таләпләренә таянып алып барырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин